РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

423646 Республика Татарстан, Менделеевский район, д.Псеево
ул. Центральная, д.4

423646 Татарстан Республикасы, Менделеевск районы,
Песәй авылы, Үзәк урам,4 йорт

Тел. (факс): (85549) 3-71-22 e-mail: Psv.Men@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 ноябрь 2019 ел № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча
Менделеевск муниципаль районының
Песәй авыл җирлегенең
Песәй авылында гражданнар җыенын
билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының муниципаль берәмлеге Песәй авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 30 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2. 2019 елның 30 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Үзәк, Мичурин урамы буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2019 елның 30 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Тукай, Чишмә, Степная урамнары, Степная тыкрыгы гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. Җыеннарның барлык этапларын үткәрү урыны итеп Песәй авыл мәдәният йортын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Песәй авылы, Мәктәп тыкрыгы, 3 й.

   Песәй авылында яшәүчеләрнең исемлеген җыеннар этапларына территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә җитештерергә:

Беренче этап: Яшьләр урамы № 1 йорттан № 28 йортка кадәр, Яшьләр тыкрыгы № 3 йорттан №5 йортка кадәр.

Икенче этап: Мичурин урамы №1 йорттан № 27 йортка кадәр, Үзәк урамы № 1 йорттан № 19 йортка кадәр.

Өченче этап: Тукай урамы №1 йорттан № 37 йортка кадәр, Чишмә урамы № 1 йорттан №13 йортка кадәр, Степная урамы № 1 йорттан № 16 йортка кадәр, Степная тыкрыгы № 1 йорттан № 9 йортка кадәр.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2019 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, I һәм II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылар, тәрбияләрендә балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләр, көндезге (көндезге бүлек) уку формалары студентлары өчен, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнарга бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм әлеге категория гражданнар өчен 150 сум күләмендә билгеләргә, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

1) Юлларны кардан чистарту
2) Вак таш сатып алу
3) Вак таш тигезләү
4) Һәйкәлне ремонтлау
5) Ясалма тигезсезлек, билгеләр урнаштыру
6) Агачлар кисү
7) Скважина насосы сатып алу
8) Чүплекне рекультивацияләү.

ӘЙЕ» «ЮК»

6. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Песәй авыл җирлеге» бүлегендә кабул ителгән көннән 3 көн эчендә урнаштырырга.
7. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Песәй авыл җирлеге башлыгы Мөхәммәтгалиев В. И.